# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасында тышкы
сәүдә эшчәнлеге турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасында тышкы сәүдә сәясәтенең һәм тышкы сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуның нигезләрен, тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучылар тарафыннан аны гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен билгели.

## 1 бүлек
## Гомуми нигезләмәләр

### 1 статья. Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр

Әлеге Законда түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

**"тышкы сәүдә эшчәнлеге"** - дәүләт тарафыннан җайга салынучы һәм экспорт, импорт һәм товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр, мәгълүматлар, акыл эшчәнлеге нәтиҗәләре белән халыкара алмашу өлкәсендә гамәлгә ашырылучы тышкы икътисадый эшчәнлек рәвешләренең берсе;

**"тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучылар"** - тышкы сәүдә эшчәнлегендә үзебезнең ил катнашучылары һәм тышкы сәүдә эшчәнлегендә чит ил катнашучылары;

**"тышкы сәүдә эшчәнлегендә үзебезнең ил катнашучылары"** (алга таба текстта - үзебезнең ил затлары) - Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы территориясендә даими урыны булган хокукый затлар, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы территориясендә даими яисә күпчелек вакытка яшәү урыны булган һәм шәхси эшкуарлар сыйфатында теркәлгән физик затлар;

**"тышкы сәүдә эшчәнлегендә чит ил катнашучылары"** - (алга

таба текстта - чит ил затлары) - башка хокукый рәвешле юридик затлар һәм оешмалар, аларның гражданлык хокукына сәләтләре үзләрен гамәлгә куйган чит дәүләт хокукы буенча билгеләнә; физик затлар - чит ил гражданнары, аларның гражданлык хокукына сәләтләре һәм хокукый гамәлләргә сәләтләре чит дәүләт гражданының үз дәүләте хокукы буенча билгеләнә; гражданлыгы булмаган затлар - аларның гражданлык хокукына сәләтләре һәм хокукый гамәлләргә сәләтләре даими яшәү урыны булган чит дәүләт хокукы буенча билгеләнә.

2 статья. Әлеге Законның бурычлары

Әлеге Законның бурычлары, Татарстан Республикасының икътисадын үстерүгә һәм аның икътисадый мәнфәгатьләрен яклауга кызыксындыру максатларында тышкы сәүдә эшчәнлегенең нәтиҗәле үсеше өчен шартлар тәэмин итүдән гыйбарәт.

3 статья. Тышкы сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыру принциплары

Татарстан Республикасында тышкы сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыруның төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- тышкы сәүдә эшчәнлегендә барлык катнашучыларның тигез хокуклылыгы;
- эшкуарлык иреге;
- гадел икътисадый хезмәттәшлек итү һәм үзара файда;
- үз табигый байлыкларына һәм тышкы сәүдә эшчәнлегенә карата дәүләтнең суверен булуы;
- тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучыларның хокукларын законсыз чикләүләрдән гарантияләү.

4 статья. Татарстан Республикасының тышкы сәүдә эшчәнлеге нигезләре

Татарстан Республикасының чит дәүләтләр, чит федератив дәүләтләрнең субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территория төзелмәләре белән сәүдә-икътисадый мөнәсәбәтләре гомумтанылган принциплар һәм халыкара хокук нормалары нигезендә корыла.

## 2 бүлек

## Тышкы сәүдә эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасының вәкаләтләре

<u>5 статья.</u> Татарстан Республикасы карамагында гына булган мәсьәләләр

Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе карамагындагы тышкы сәүдә эшчәнлегеннән тыш һәм уртак карамактагы эшләр буенча Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш, тышкы сәүдә эшчәнлеген җайга салу өлкәсендә тулысынча дәүләт хакимиятенә ия.

Татарстан Республикасы үз вәкаләтләре чикләрендә:

- үз территориясендә тышкы сәүдә эшчәнлеген законнар нигезендә җайга сала;

- тышкы сәүдә эшчәнлеген үстерә һәм тикшереп тора;

- тышкы сәүдә эшчәнлеге буенча республика программаларын эшләүне һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

- чит дәүләтләр, чит федератив дәүләтләрнең субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территория төзелмәләре белән сәүдә-икътисадый килешүләр төзи;

- Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән чит дәүләтләрдә халыкара хокук нормаларына каршы килмәгән рәвештә, сәүдә вәкиллекләре төзи;

- Татарстан Республикасы Хөкүмәте гарантияләвендә дәүләт, банк һәм коммерция кредитларын, ссудаларны тарта, алардан файдалануны һәм кайтарып бирүне тикшереп тора;

- Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучыларга гамәлдәге законнар нигезендә гарантияләр һәм ташламалар бирә;

- халыкара икътисадый һәм финанс оешмаларының эшендә катнаша;

- чит илдә Татарстан Республикасының дәүләт милкенә ия була, аңардан файдалана һәм аңа идарә итә.

3 бүлек

Тышкы сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу

6 статья. Тышкы сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуны гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органнары

Татарстан Республикасы тышкы сәясәтенең бер өлеше булараk, дәүләт тышкы сәүдә сәясәте юнәлешләре һәм өстенлекләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы Президенты:

- Татарстан Республикасының тышкы сәүдә буенча дәүләт сәясәтенә җитәкчелек итә һәм тышкы сәүдә эшчәнлегенең төп өстенлекләрен билгели;

- Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары тарафыннан йөкләнгән, шулай ук Татарстан Республикасының халыкара йөкләмәләреннән килеп чыгучы бүтән вәкаләтләрне башкара;

- нефть продуктларын һәм башка стратегик товарларны чит илгә чыгаруның өстәмә шартларын билгели;

- Татарстан Республикасының дәүләт органнары һәм тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучылар арасында фикер каршылыкларын хәл итү өчен килештерү процедураларыннан файдалана.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты:

- үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасында дәүләтнең тышкы сәүдә эшчәнлеге сәясәтен уздыруны тәэмин итә һәм аны гамәлгә ашыру чараларын күрә, тиешле карарлар кабул итә һәм аларның үтәлешен тәэмин итә;

- тышкы сәүдә эшчәнлеген үстерү программасын әзерли һәм аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раславына тәкъдим итә;

- Татарстан Республикасының чит дәүләтләр, чит федератив дәүләтләрнең субъектлары, чит дәүләтләрнең административ-территория төзелмәләре белән сөйләшүләр алып баруы һәм сәүдә-икътисадый килешүләр төзүе хакында үз вәкаләтләре чикләрендә карарлар кабул итә;

- Татарстан Республикасының чит илләрдәге дәүләт милкенә идарә итә;

- тышкы сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә үз вәкаләтләре чикләрендә башка гамәлләрне тормышка ашыра;

- Татарстан Республикасының эчке базарын саклау буенча вакытлы чаралар күрә;

- таможня тарифы ставкалары күләмен үзгәртү турында мәсьәләне куя;

- килешүләр нигезендә чит дәүләтләрдә Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый вәкиллекләрен булдыру турында карарлар кабул итә;

- чит дәүләтләрдә һәм халыкара икътисадый оешмаларда Татарстан Республикасы вәкаләтләрен билгели һәм аларны чакыртып ала;

Татарстан Республикасының тышкы сәүдә эшчәнлеге буенча дәүләт сәясәте турында, тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучыларның тышкы сәүдә эшчәнлеген җайга салу, Татарстан Республикасының чит дәүләтләр белән, чит федератив дәүләтләрнең субъектлары, чит дәүләтләрнең административ территория төзелмәләре белән сәүдә-икътисадый килешүләр төзүе турындагы тәкъдимнәр әзерләүне үзенә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан тышкы сәүдә эшчәнлеген яраштыру һәм җайга салу йөкләнгән Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе органы. Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең,үз компетентлылыгы чикләрендә, башка органнары белән берлектә башкара.

<u>7 статья.</u> Тышкы базарларга чыгу өчен уңай шартлар тудыру

Татарстан Республикасы Хөкүмәте үз вәкаләтләре кысаларында һәм үзенең вәкаләтле органнары аша үз илебез затларына чит дәүләтләрнең базарларына чыгар өчен уңай шартлар тудыру буенча чаралар күрә, шушы максатларда ул ике яклы һәм күп яклы сөйләшүләр алып бара, халыкара икътисадый шартнамәләр төзи, шулай ук Татарстан Республикасының чит дәүләтләр белән сәүдә-икътисадый бәйләнешләрен үстерүгә ярдәм итүче халыкара органнар һәм хөкүмәтара комиссияләр төзүдә һәм аларның эшчәнлегендә катнаша.

4 бүлек

Тышкы сәүдә эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итү һәм аны стимуллаштыру

<u>8 статья.</u> Тышкы сәүдә эшчәнлегенең мәгълүмати тәэмин ителеше

Татарстан Республикасында тышкы сәүдә эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм үстерү максатларында тышкы сәүдә мәгълүматы системасы эшли, аңа әлеге Законның 6 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы идарә итә.

Тышкы сәүдә турындагы мәгълүматлар системасында түбәндәге белешмәләр була:

- тышкы сәүдә эшчәнлеген үстерү буенча республика программалары турында;
- Татарстан Республикасының тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучылар турында;
- тышкы сәүдә эшчәнлеге өлкәсендәге законнар турында;
- чит илләрдә Татарстан Республикасы вәкилләкләренең эшчәнлеге турында;
- чит ил базарларындагы төп товар төркемнәре буенча конъюнктура турында;
- тышкы сәүдә эшчәнлеген алып бару өчен кирәкле бүтән белешмәләр.

<u>9 статья.</u> Тышкы сәүдә эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итүче гамәлләр

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, шулай ук ул вәкаләтләр биргән органнар тышкы сәүдә эшчәнлеген үстерүгә булышлык итүче гамәлләрне тормышка ашыра, аларны тиешенчә финанслый, моңа түбәндәгеләр керә:

- тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучыларны кредит белән тәэмин итү;
- сәүдә күргәзмәләре һәм ярминкәләре, махсус симпозиумнар һәм конференцияләр оештыру, аларда катнашу;

- реклама кампанияләре һәм товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне, экспортлауны арттыру буенча кампанияләр уздыру;

- тышкы сәүдә эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар системасын һәм мәгълүмати-киңәшләшү хезмәтләре булдыруны, шулай ук тышкы сәүдә эшчәнлегенә кызыксындырырлык һәм шуңа омтылыш тудырырлык башка ысулларны гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

- тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучыларның хөкүмәтнеке булмаган халыкара оешмалары эшчәнлегендә әлеге оешмаларның устав документларында каралган тәртиптә һәм законнарны үтәгән килеш катнашулары.

<u>10 статья.</u> Тышкы сәүдә эшчәнлегендә иминләштерү

Дәүләт һәм аның органнары экспортны һәм импортны хуплау, импортны кире кайтару программасы кысаларында валюта һәм кредит хәвеф-хәтәрләреннән иминләштерелергә хаклы.

Тышкы сәүдә эшчәнлеге өлкәсендәге коммерция хәвеф-хәтәрләрен һәм коммерциягә карамаган хәвеф-хәтәрләрне иминләштерү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

<u>11 статья.</u> Тышкы сәүдә турындагы статистика

Татарстан Республикасының Статистика буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасының Милли банкы, Россия Федерациясе Дәүләт таможня комитетының Татарстан таможня идарәсе дәүләтнең бердәй статистика хисабы нигезендә Татарстан Республикасының тышкы сәүдә күләмнәре, товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне чит илләргә чыгару, чит илләрдән кертү күләмнәре турында һәм Татарстан Республикасы территориясендә чит ил инвесторлары катнашында гамәлгә куелган хокукый затларның эшчәнлеге турында Россия Федерациясенең Статистика буенча дәүләт комитеты тарафыннан, Россия Федерациясенең Үзәк банкы һәм Россия Федерациясенең Дәүләт таможня комитеты тарафыннан әзерләнгән һәм расланган ысулият буенча статистика хисабы һәм мәгълүматы системасын оештыруны тәэмин итәләр.

12 статья. Тышкы сәүдә эшчәнлеге үсешенә ярдәм итүче берләшмәләр

Тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучылар тармак, территория һәм башка принциплар буенча ихтыяри рәвештә ассоциацияләргә, сәүдә һәм сәнәгать палаталарына, башка берлекләргә берләшә алалар. Тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучылар ассоциацияләре һәм берлекләре әгъзаларының мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү, аларның гомуми мәнфәгатьләрен күрсәтү уставларында һәм бүтән документларында каралган максатлары, вәкаләтләре һәм вазифалары нигезендә башка бурычларны хәл итү, әлеге Законның 9 статьясын үтәп, тышкы сәүдә эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыру өчен төзелә.

Тышкы сәүдә эшчәнлегендә катнашучыларның берләшмәләрен төзү һәм аларның эшчәнлеге гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә җайга салына.

Чит дәүләтләр, чит федератив дәүләтләрнең субъектлары, чит дәүләтләрнең административ - территория төзелмәләре белән тышкы сәүдә бәйләнешләрын үстерү максатларында уртак сәүдә һәм сәнәгать палаталары гамәлгә куелырга һәм Татарстан Республикасы территориясендә аларның вәкилләкләре ачылырга мөмкин.

13 статья. Татарстан Республикасында чит ил хокукый затларының вәкилләкләре

Чит ил хокукый затлары, бары тик шушы хокукый затлар исеменнән тышкы сәүдә эшчәнлеге алып бару өчен, гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасында вәкилләкләр ачарга хаклы.

## 5 бүлек

## Тышкы сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тикшереп тору. Тышкы сәүдә эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы законнарын бозган өчен җаваплылык

14 статья. Тышкы сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тикшереп тору

Әлеге Законның һәм тышкы сәүдә эшчәнлеге турында башка хокукый һәм норматив актларның нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итү һәм Татарстан Республикасының, шулай ук үзебезнең ил затларының икътисадый мәнфәгатьләрен яклау максатларында Татарстан Республикасының тиешле органнары үз вәкаләтләре чикләрендә тышкы сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тикшереп торалар.

15 статья. Тышкы сәүдә эшчәнлеге турындагы законнарны бозуда гаепле затларның җаваплылыгы

Тышкы сәүдә эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы законнарын бозуда гаепле затлар законнар нигезендә хокукый җаваплылыкка тартылалар.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 11 июле
N 694

3 termin.txt